Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлегенең
Колшәрип авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карары

21 ноябрь 2022 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2022 елның 19 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта, 2022 елның 19 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта, 2022 елның 19 ноябрендә 12 сәгать 00 минутта, 2022 елның 19 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта, 2022 елның 19 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге “Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлеге Колшәрип авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: Колшәрип авылында юлларны, урам утларын, су белән тәэмин итү системасын норматив хәлгә китерү, смета төзү, техник күзәтчелек үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү өчен түләү?” соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 1610 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 821 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 821 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның 0 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлегенең Колшәрип авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2.«Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Колшәрип авыл җирлеге Колшәрип авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару: Колшәрип авылында юлларны, урам утларын, су белән тәэмин итү системасын норматив хәлгә китерү, смета төзү, техник күзәтчелек үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү өчен түләүгә ризамы?” турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Колшәрип авылы, Тукай урамы, 50 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Колшәрип авыл җирлеге башлыгы А.Ф. Кәшәфетдинов